**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Иске Үтәмеш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге составына керүче
Иске Үтәмеш торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**17 октябрь 2023 ел** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 17 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде киләсе мәсьәлә буенча:

1. «2024 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Иске Үтәмеш торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган һәм даими яшәүче кешегә 1600 сум күләмендә үзара салым кертергә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, шулай ук мобилизацияләнгән гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Иске Үтәмеш торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Иске Үтәмеш авылында су башняларын, скважиналарны, «Мәликә», «Атау» чишмәләрен ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, койманы төзү, ремонтлау һәм буяу, су башнясын буяу, павильонны төзү, тышлау, каты өслекле юллар төзү, проект-смета документациясе өчен түләү) Иске Үтәмеш торак пунктында скважиналарны һәм каптажны лицензияләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.
- Иске Үтәмеш торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, агрегатлар сатып алу, хезмәтләргә түләү, торак пункт урамнарын җәйге тоту, триммерлар, ягулык-майлау материаллары сатып

алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар;

- Иске Үтәмеш торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (балалар мәйданчыкларын, спорт мәйданчыкларын, паркларны, яр буйларын) төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү, Югары Чегодай торак пунктында адрес такталарын ясау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 285 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 180 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 180 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге составына керүче Иске Үтәмеш торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2024 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Иске Үтәмеш торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган һәм даими яшәүче кешегә 1600 сум күләмендә үзара салым кертергә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, шулай ук мобилизацияләнгән гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Иске Үтәмеш торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Иске Үтәмеш авылында су башняларын, скважиналарны, «Мәликә», «Атау» чишмәләрен ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, койманы төзү, ремонтлау һәм буяу, су башнясын буяу, павильонны төзү, тышлау, каты өслекле юллар төзү, проект-смета документациясе өчен түләү) Иске Үтәмеш торак пунктында скважиналарны һәм каптажны лицензияләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.

- Иске Үтәмеш торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, агрегатлар сатып алу, хезмәтләргә түләү, торак

пункт урамнарын җәйге тоту, триммерлар, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар;

- Иске Үтәмеш торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (балалар мәйданчыкларын, спорт мәйданчыкларын, паркларны, яр буйларын) төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү, Югары Чегодай торак пунктында адрес такталарын ясау.

3. Әлеге карарны Иске Үтәмеш, Муса Җәлил урамы, 54 нче йорт адресы буенча мәгълүмати стендларда һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Утәмеш авыл җирлегенең Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.С.Мингулов